**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«___10___» _____02_____ 2026 ел.** **№ ___47_____**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Сарлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 28 статьяларына, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, "Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы карары белән расланган "Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Сарлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны (алга таба - гавами тыңлаулар) билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп - Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

3. Генераль план проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5. Гавами тыңлауларны уздыру чорын - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлауларны уздыру вакыты бер айдан да артык була алмый.

6. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча»: http://aznakaevo.tatar.ru һәм шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы Башлыгы карарына кушымта
«_10___»_____02___2026 №___47__

Генераль план проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районының "Административ хуҗалык идарәсе" МБУ баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Ханнанов Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы җирлекләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе |
| Камалетдинов И.М. | Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шәрипов М.Р. | Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |